БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 04 2026 ел № 162

Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасының икътисад, социаль өлкә, дәүләт һәм муниципаль идарә тармакларының алдынгы ИТ-карарлары» региональ проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә инженерлык челтәрләрен вектор форматында цифрлаштыру проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 20 августындагы 264 номерлы карары белән расланган җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Регламентның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.7 пункт өстәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.»;

1.2. Регламентның 2.5.2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 нче пунктчаны өстәргә:

«mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендәге җир эшләренең чикләре (полигоны) яки җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар түбәндәге ысулларның берсе белән:

16 МСК системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;

территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;

картографик яисә топографик нигездә эш башкару урынының чикләре схемасы.»;

1.3. Регламентның 2.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендәге җир эшләренең чикләре (полигоны) яки җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар түбәндәге ысулларның берсе белән:

16 МСК системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;

территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;

картографик яисә топографик нигездә эш башкару урынының чикләре схемасы.»;

1.4. Регламентның 2.5.5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Башкарылган төшерүдә күрсәтелә торган инженерлык челтәрләре һәм Татарстан Республикасы инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» 2025 елның 16 сентябрендәге 1308 номерлы боерыгында бәян ителгән һәм җир эшләре чикләрендә төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслеге һәм тулылыгы мәсьәләсенә ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән векторлы модель структурасы нигезендә тутырылган семантика белән МСК-16 координаталар системасында яки WGS 84 (EPSG:3857) вектор форматында җир эшләре чикләрендә 1:500 масштабында башкарылган төшерү.»;

1.5. Регламентның 2.5.6 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Башкарылган төшерүдә күрсәтелә торган инженерлык челтәрләре һәм Татарстан Республикасының инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» 2025 елның 16 сентябрендәге 1308 номерлы боерыгында бәян ителгән һәм җир эшләре чикләрендә төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслеге һәм тулылыгы мәсьәләсенә ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән векторлы модель структурасы нигезендә тутырылган семантика белән МСК-16 координаталар системасында яки WGS 84 (EPSG:3857 вектор форматында җир эшләре чикләрендә 1:500 масштабында башкарылган төшерү.»;

1.6. Регламентның 2.8.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пунктча белән тулыландырырга: «Регламентның 2.6.1-2.6.6 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать итүченең үзе тәкъдим итәргә тиешле документларны тәкъдим итмәве, яки каршылыклы мәгълүматлар булган яки бу Регламентның 2.5.6 пункты 2 нче пунктчасы таләпләренә туры килмәгән документларны тәкъдим итүе»

1.7. Регламентның 3.5.2.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турындагы карар «ТР пространстволы планлаштыру институты» ДБУ белән мәҗбүри килештерелергә тиеш.»

1.8. 3.3.3.1., 3.4.4., 3.5.2.1., 3.5.2.2 пунктларында «электрон документлар әйләнеше системасы аша» сүзтезмәсен «ГИСОГД системасы аша» сүзтезмәсе белән алыштырырга;

1.9. 3.5.3 пунктында «электрон документ әйләнеше системасында» дигән сүзтезмәне «ГИСОГД системасында» дигән сүзтезмәгә алыштырырга;

1.10. Регламентка 1 нче кушымтаны, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.11. Регламентка 2 нче кушымтаны, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.12 Регламентка 3 нче кушымтаны, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.13. Регламентка 12 нче кушымтаны, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.14. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә 14 нче кушымта өстәргә;

1.15. Әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә 15 нче кушымта өстәргә;

1.16. Әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә 16 нчы кушымта өстәргә;

1.17. Әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә 17 нче кушымта өстәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның « 17 » 04
162 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Тышкы төзекләндерү элементлары бозылу белән бәйле җир эшләрен башкару өчен _______ номерлы ордер**

«_____» ________________20____ ел.

Заказ бирүче:______________________________________________________________

Эшләр башкаручы: ___________________________________________________________

Подрядчының адресы һәм телефоны:

___________________________________________________________________________

Субподрядчының адресы һәм телефоны:

___________________________________________________________________________

Җир эшләрен башкару рөхсәт ителә ____________________________________________

___________________________________________________________________________

Җир эшләрен башкару адресы: _________________________________________________

___________________________________________________________________________

Эшләрне башкару тәртибе һәм ысулы:

___________________________________________________________________________

Яшел зонадагы эшләргә таләпләр:

Зыян килгән: _________ кв.м. юл капламы, __________ кв.м. асфальт капламы, ________ кв.м. газон мәйданы.

Җир эшләрен башкару рөхсәт ителә: **20_____елның «___»___________ алып 20__ елның «___»__________ кадәр**

Тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле рәвештә җир эшләрен башкаруга ордерны ябу һәм төзекләндерү эшләрен 20__ елның «___»_________ кадәр башкару.

Җитәкче ____________________

Ордерга кушымта
жаваплы зат (прораб, мастер) тарафыннан тутырыла.

Мин, ____________________________________________________________________,
(Ф.И.О., вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

эшләр башкарыла башлауга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакыруны, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу Кагыйдәләре нигезендә башкаруны, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәүне һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкаруны үз җаваплылыгыма алам. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тотарга әзер.

Эшләрне башкару өчен төп таләпләр турында белешмәлек белән танышмын.

Эшләрне башкаручы ___________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

«__» __________ 202__ ел.

**Белешмәлек**

1. Эшләр башланганчы җир эшләре башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрнең башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмага хәбәр итә. Заказ бирүче (төзүче) подрядчыга эшләр башкаруга ордер рәсмиләштерергә вәкаләт бирергә хокуклы.

2. Бозылган юл өслекләрен, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3. Объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен эксплуатациягә кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә аска инү һәм формасын югалту очраклары булганда торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланып, өч көн эчендә тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң, __________ һәм заказчы вәкилләре тарафыннан имзаланган төзекләндерүне торгызу буенча эшләрне кабул итү акты белән объектны тапшыра.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы койма белән әйләндереп алынырга тиеш, участок билгеләнгән проект белән ______________________________________ килештерелгән чикләрдә урнаштырылырга тиеш.

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына һәм торак биналарга керү юллары буш булырга, траншеялар аша чыгу күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар материал төре буенча штабельгә өелеп сакланырга һәм траншея җире белән кушылмаска тиеш, шулай ук урам хәрәкәтенә комачауламаска тиеш. Кире тутыру өчен яраксыз булган траншея җирен эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр белән чокырларны 0,2 м калынлыктагы комлы грунт катламы белән күмәргә, җентекләп тыгызларга һәм су сибеп торырга кирәк (җәй вакытында). Кыш көннәрендә траншеяларны һәм чокырларны тыгызлап, эрегән комлы грунт белән тутыру мәҗбүри.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җавап тота.

Эшләрне башкаручы ______________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» 04
162 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Тышкы төзекләндерү элементларының бозылуына бәйле авария-торгызу эшләрен башкаруга**
**_________ номерлы ОРДЕР**

«__»____________________20_____ ел

Заказ бирүче

_____________________________________________________________________________

(юридик затлар өчен оешма исеме, ИНН/ мөрәҗәгать итүченең физик затлары өчен)

Эшләр башкаручы:

_____________________________________________________________________________

(оешманың исеме, җаваплы затның ФИО, телефон)

Эшләр төре:___________________________________________________________

Эшләрне башкару адресы:_______________________________________________

Бу нигездә ____________________________________________________________,
___________________________________________ «_____» _______________
20___ел № ___ белән килештерелгән.

Эшләрне башкару тәртибе һәм ысулы:

_____________________________________________________________________________

Яшел зонадагы эшләргә таләпләр:

Зыян килгән: _________ кв.м. юл капламы, __________ кв.м. асфальт капламы, ________ кв.м. газон мәйданы.

Ордер билгеләнгән вакыт дәвамында гамәлдә була. Эшләр ордерны тулысынча рәсмиләштергәннән соң гына башкарылырга тиеш.

Җитәкче _______________________________

Ордерга кушымта
жаваплы зат (прораб, мастер) тарафыннан тутырыла.

Мин, ________________________________________________________________________,
(Жаваплы затнын Ф. И. А., вазыйфасы, эш урыны)
эшләр башкарыла башларга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакырырга, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу кагыйдәләре нигезендә башкарырга, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәргә һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкарырга вәгъдә бирәм. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җавап тотарга әзер.

Эшләрне башкарганда төп таләпләр турындагы Белешмәлек белән таныштым.

Эшләрне башкаручы______________________________________________________________
(Җаваплы затнын Ф. И. А., вазыйфасы, эш урыны)

«__» __________ 202__ ел

Белешмәлек

1. Эшләр башланганчы җир эшләре башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрнең башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы Оешмага хәбәр итә. Заказ бирүче (төзүче) подрядчыга эшләр башкаруга ордер рәсмиләштерергә хокуклы.

2. Бозылган юл өслекләрен, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3. Корылмалар һәм деформацияләр килеп чыкканда объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен эксплуатациягә кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланганнан соң өч көн эчендә объектны тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң төзекләндерүне торгызу буенча эшләрне кабул итү акты белән тапшыра.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы коймa белән әйләндереп алынырга тиеш, участок проект белән килештерелгән чикләрдә урнаштырылырга тиеш.________________________________________________________________

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына керү һәм торак биналарга керү юллары буш булырга, траншеялар аша күчеш күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар материаллар төрләре буенча штабельләргә салынырга һәм траншеяләрдәге җир белән кушылмаска һәм урам хәрәкәтенә комачауларга тиеш түгел. Кире күмү өчен яраксыз булган траншеяләрдәге грунтны эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр һәм чокырлар 0,2 м калынлыктагы комлы грунт белән күмелергә, җентекләп тыгызланырга һәм су сибелергә тиеш (җәй көне). Кыш көне траншеяларны һәм чокырларны тыгызлап эрегән комлы грунт белән күмәргә кирәк.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

Эшләрне башкаручы ___________________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20 26 елның « 17 » 04
162 номерлы карарына
3 нче кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча
мцниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту хакында
КАРАР

____________ номерлы гариза белән________________________________________________

_____________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

_______________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затның– мөрәҗәгать итүченең исеме)

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Җитәкче _______________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» 04
162 номерлы карарына
4 кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча
мцниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту хакында
КАРАР

___________ номерлы гариза белән_______________________________________________

_____________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

_________________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затнын– мөрәҗәгать итүченең исеме)

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Җитәкче ___________________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» 04
162 номерлы карарына
5 нче кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу срогын озайту турында**
**_______ номерлы ХӘБӘРНАМӘ**

20___ елның «____» _____________ ___________ номерлы гариза белән________________

____________________________________________________________________________

_____________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

____________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затның– мөрәҗәгать итүченен исеме)

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу вакытын 20___ елның «____» _____________ нан озайту турында карар кабул ителде.

Җитәкче ___________________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» 04
162 номерлы карарына
6 кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында**
**_______номерлы ХӘБӘРНАМӘ**

20___ елның «____» _____________ ___________ номерлы гариза белән_______________

___________________________________________________________________________

____________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

___________________________________________________________________________

(Физик затнын Ф.И.А., юридик затның – мөрәҗәгать итүченең исеме)

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча 20__елның «____» ___________ нан җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында карар кабул ителде.

Җитәкче _________________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» 04
162 номерлы карарына
7 кушымта

**Тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләренең гамәлдә булу срогын үзгәртү һәм башкару турында белешмәләрне җир эшләрен башкару ордерына кертү хакында _______номерлы ХӘБӘРНАМӘ**
**(кышкы чорда)**

20___ елның «____» ______________ ___________ номерлы гариза белән________________

_____________________________________________________________________________________

______________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

_____________________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затның – мөрәҗәгать итүченең исеме)

Тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләренең гамәлдә булу срогын үзгәртү һәм башкару турында белешмәләрне җир эшләрен башкару ордерына кертү хакында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу вакытын 20___ елның «____» ______________ на кадәр үзгәртү турында карар кабул ителде. Тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләрен башкаруга кагылышлы белешмәләргә үзгәрешләр кертергә, аерым алганда: ________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

Җитәкче ____________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «17» ____04____
162 номерлы карарына
8 кушымта

**ҖИР ЭШЛӘРЕН БАШКАРУГА ОРДЕРНЫ ЯБУ турында муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында**
**_______ номерлы КАРАР**

20___ елның «____» ______________ ___________ номерлы гариза белән________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_(Физик затның Ф.И.А., юридик затның – мөрәҗәгать итүченең исеме)
мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә
тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде : _______________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Җитәкче ____________________